Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге составына керүче Прости торак пунктында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елның 24 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлегенең Прости торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Прости авыл җирлеге Прости торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли.

2. Алынган акчаларны Мәктәп урамы буенча автомобиль юлының юл полотносын асфальт белән чокырларны ямауга (килешү буенча түләү), мөселман зиратына алып баручы юлга вак таш җәюгә (китерү килешүе буенча вак таш сатып алу; килешү буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү), һәм Луговая, Зеленая, Гагарин һәм 2нче Дачная урамнары буенча вак таш җәелгән юлларга вак таш җәюгә (китерү килешүе буенча вак таш сатып алу; килешү буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү) юнәлтергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Прости авыл җирлеге башлыгы Д.А. Бәдәртинов